КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 июль г.Казань № 653

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча экспериментта Татарстан Республикасының катнашуы хакында» 2021 ел, 12 март, 123 нче карары белән расланган оператив штаб составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча экспериментта Татарстан Республикасының катнашуы хакында» 2021 ел, 12 март, 123 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча эксперимент үткәрүнең оператив штабы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оператив штаб составыннан А.Р.Мөгыйновны, Т.Ф.Хөснетдиновны чыгарырга;

оператив штаб составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры, оператив штаб рәисе урынбасары Фәнил Әнвәр улы Әһлиуллинны;

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе Динар Рәшит улы Сәмигуллинны (килешү буенча);

Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасындагы һәм Ульяновск өлкәсендәге Төбәкара территориаль идарәсенә караган

федераль мөлкәтне исәпкә алу, аның белән идарә итү һәм аны хосусыйлаштыру бүлеге башлыгы Нәфис Ринат улы Җиһангәрәевны (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин